

Кvптән тvгел юбилей датасын РМ гомуми белем бирv мактаулы хезмәткәре, Мордовиянен атказанган укытучысы Тянзилә Әхмәт кызы Утешева билгеләп vтте.

Бу унайдан юбилярнын тормыш юлына тукталырга уйлаган идем. Тик 40 елдан артык гомерен педагогикага багышлаган кеше белән әнгәмә, ничек кенә читкә китәргә тырышма, һаман да шул эшкә килеп тортелде. Чонки анын ботен гомере хезмәт белән бәйле.Бу ниндидер чик һәрвакыт бәяләргә, бvгенгесе турында уйларга һәм киләчәкне билгеләргә момкинлек бирә. Ул vзенә кыйммәтле педагогик тәҗрибә, нәтиҗәле идарә итv практикасы, зур белем кvләме, чын-чынлап яшь буынны укыту һәм тәрбияләv эшенә рухи монәсәбәтне бер- ләштерә. Кырык елдан артык язмыш бу зыялы, гадел һәм сизгер хатын-кызны мәгариф белән бәйли. Торбеево районы Татар Юнки топ мәктәбе – бу белем бирv урыны матур, жылы, унайлы һәм кунакчыл булсын очен кулдан килгәннен барысын да эшли.      Ачык йозле һәм энергияле яшь кыз, Зубово-Поляна педагогия училищесын тәмамлаган сон, 1980 елларда, туган авылына эшкә кайта. Әйтерсен кичә ышанычлы һәм таныш уку йорты бусагасын атлап кергәндәй, әлбәттә, укытучылар коллективына гармонияле йогынты ясаган. 1986 елда М.Е.Евсевьев исемендәге МГПИнын химия – биология факультетын тәмамлап туган авылы мәктәбендә хезмәтен дәвам итә. Үзе укыган, эшләгән мәктәбен 1989 елда житәкли. Нәкъ менә шушы чор илебез һәм анын халкы тарихында катлаулы чорларнын vзгәртеп кору, базар икътисады- на кvчv чоры. Тирән трансформация процесслары мәгариф кинлегендә дә барды. Яшь директор бу мизгелнен ботен авырлыгын vз жилкәләрендә сынаган, тик беркайчан да анын алдына килеп баскан проблемаларны кул астындагылар жилкәсенә салмаган.

- Туксанынчы еллар башында дәvләт бюджетында финанслау кытлыгы зур булды. Әмма туган авырлыкларга карамастан, мәктәбебез ашханәсен реконструкцияләдек һәм vзгәртеп кордык, капиталь ремонт ясаттык һәм сыйныф бvлмәләрен сыйфатлы жиһазлар белән тутырылды, китапханә-не дәреслекләр һәм китаплар белән тәэмин итәргә туры килде. Кечкенә улымны, Дамирымны, йокларга яткырып, тоннәрен язма

остәл артында утырып, киләчәккә планнар кора торган идем. Коллективым белән бергә, балаларны файдалы, моһим, кирәкле нәрсәләргә ойрәтv, аларга игелек лелек, кызыксынучанлык, кешелеклелек тәрбияләргә тырыштык; нәтижәдә һәр баланы шәхескә әйләндерергә, тиешле белемгә омтылышларын югалтмау очен кулдан килгәннен барысын да эшләдек, - дип искә ала әнгәмәдәшем.
Нык, таләпчән, vжәт холыклы, ул vз тирәсенә ижади, битараф булмаган, югары квалификацияле белгечләрне берләштерә, яшь кадрларны жәлеп итә, аларга һәрь яклап ярдәм итә, эш очен унай шартлар тудыра. Аерым алганда, танылган Шамиль Тарпищев ярдәме белән, 2009 елда, заманча спорт залы тозегәннәр. Бvген мәктәптә мәгълvмати технологияләр һәм инновацион укыту методлары кертелә, матди-техник база камилләштерелә.
Тәжрибәле педагоглар ярдәме белән мәк- тәп укучылары интеллектуаль һәм спорт ярышларында, фән олимпиадаларында, патриотик смотрларда, конкурсларда, концертларда һәм фестивальләрдә актив катнашалар. Мәсәлән, Татар Юнки гомуми белем бирvче топ мәктәбенен укучылары, югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары Альфия Мәхмvт кызы Агишева житәкчелегендә, регионыбыз татар теле һәм әдәбияты фәннәре олимпиадаларында еш призлы урыннар алып торалар. Мәктәптә милли мәдәният музее эшли, ачык дәресләр vткәрелә, семинарлар, викториналар, әдәби-музыкаль кичәләр, мәгърифәтчелек лекцияләре, конференцияләр, спектакльләр, эксперименталь дәресләр оештырыла. Тянзилә Әхмәтовнанын биология дәресләре эч-тәлекле, кызыклы vтә. Ул һәр яшь буын вәкиленә якын килеп эш итә, яшь гражданнар белән тигез, әдәпле тел белән сойләшә, һәрвакыт гадел һәм ихлас. «Башкача ярамый, балалар йорәк белән тынлый һәм теләсә нинди фальшны си-зә», - дип билгеләп vтә Тәнзилә Әхмәт кызы. Тәжрибәле педагогнын һонәри осталыгын һәм сәләтләрен бернинди разрядлар һәм квалификация белән дә бәяләп булмый. Аны бик гади һәм ихластан – зур хәрефтән язылган укытучы дип атыйлар.
Илдә vзгәрешләр жиле искән вакыт, 2017елны, Торбеево районы Татар Юнки гомуми белем бирvче топ мәктәп Жуковский урта мәктәбенен филиалы була, ә Т.А.Утешева - анын заведующие. Бvген бу филиалда 1 - 9 сыйныфлардагы (3, 9 классларда укучы балалар юк) 18 укучыга 8 укытучы белем бирә. Үткән жомга конне Рособрнадзордан контрольныйлар эшләгәннәр, нәтижәләре яхшы.
Бvгенге кондә, пенсия яшендә булуына да карамастан, Татар Юнки авылы мәктәбе коллективын житәкләвен дәвам итә язма героебыз. Барлык кеше белән уртак тел табып эшли ул. Тәнзилә Әхмәт кызыннан: «Гомер буе коллектив белән ничек шулай дус эшләргә була?» – дип сорагач: «Эштән курыкмаска, балалар, коллектив, ата-аналар белән уртак тел табып; бар эшнен дә яхшы ягын, кешеләрнен дә яхшылыкларын гына кvреп эшләргә, яшәргә кирәк»,– диде ул. Алга таба да шулай булсын.

**Н.ХӘЛИЛ**